ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ЯТМАС-ДУСАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАР

“22” март 2024 ел №10

Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлегенең Беренче Май поселогында гражданнар Җыенының 29.11.2023 елдагы 1 номерлы «халыктан үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча үткәрелгән халык җыены нәтиҗәләре турында»гы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча, Беренче Май поселогында халык җыенын билгеләп кую турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында " 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Ятмас-Дусай авыл җирлеге Советы карар бирә :

1. 2024 елның 05 апрелена 14 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге Беренче Май поселогында гражданнар Җыенының 29.11.2023 елдагы 1 номерлы «халыктан үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча үткәрелгән халык җыены нәтиҗәләре турында»гы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча, Беренче Май поселогында гражданнар җыенын үткәрүне билгеләргә.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге Беренче Май поселогында авылында узара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 29.11.2023 №1 карарына үзгәрешләр кертүгә ризамы:

“Сез Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлегенең Беренче Май поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән,укучылар һәм көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан (курсантлар); I төркем инвалидлардан; 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 2024 елда үзара салымны 1000 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

-Беренче Май поселогында вак таш белән таш белән юлларны төзү, карап тоту, төзекләндерү, шул исәптән проект-смета документациясе һәм технадзорны гамәлгә ашыру;

-Беренче Май поселогында юлларны кышкы-җәйге тоту (проект-смета документациясен эшләү, килешү буенча түләү);

- Беренче Май поселогында һәйкәл төзү һәм төзекләндерү, граниттан мемориаль такталар сатып алу һәм урнаштыру (проект-смета документациясен эшләү һәм технадзорны гамәлгә ашыру);

- Беренче Май поселогында чишмә территориясен ремонтлау һәм төзекләндерү (проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру).

29.11.2023 елның 1 нче номерлы карарында күрсәтелгән эш төрләре өлешендә түбәндәге эшләр белән үзгәртергә:

- торак пункт территориясен төзекләндерү (Беренче Май поселогы территориясен төзекләндерү, проект-смета документациясе, килешү буенча эш өчен түләү, территорияне төзекләндерү буенча башка эш төрләре),

-торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау,карап тоту (юлларны вак таш белән каплап төзү, ремонтлау һәм төзекләндерү, вак таш белән каплап чокырларны ремонтлау; юлларны кардан чистарту,юлларны җәйге-кышкы карап тоту; Беренче Май поселогында юлларны төзекләндерү, карап тоту һәм төзекләндерү буенча башка эш төрләре, шул исәптән проект-смета документациясе һәм технадзорны гамәлгә ашыру)

- һәйкәлләрне төзү, ремонтлау( Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) түгел) һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү; (Беренче Май поселогында һәйкәл төзү һәм төзекләндерү, язулы граниттан мемориаль такталар сатып алу һәм урнаштыру; проект-смета документациясен эшләү һәм технадзорны гамәлгә ашыру).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге уставында билгеләнгән тәртиптә халыкка игълан итәргә , шулай ук аны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Ятмас- Дусай
авыл җирлеге башлыгы Ф. Х. Гарифуллина